РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 30 октябре Кукмара ш. № 15

«Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын билгеләү турында» Кукмара муниципаль район Советының 2019 елның 25 октябрендәге 250 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә, муниципаль хезмәтне җайга салуны камилләштерү максатларында, Кукмара муниципаль районы Советы карар **бирде**:

1. «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын билгеләү турында» Кукмара муниципаль район Советының 2019 елның 25 октябрендәге 250 номерлы карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

а) «Башкарма комитет» бүлегенең «Инфраструктура үсеше бүлеге» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| **Инфраструктура үсеше бүлеге** | |
|---|---|
| бүлек җитәкчесе | муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары |
| бүлек җитәкчесе урынбасары | муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфалары |
| баш белгеч | муниципаль хезмәтнең өлкән вазыйфалары |

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Район Башлыгы С. Д. Димитриев